БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» 10 2020 ел. № 303

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 24 октябрендәге 327 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсендәге муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салынган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында, пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Балтач муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсендәге муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны җайга салу һәм алар белән идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү максатларында, «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) шәхси эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар җитештерүчеләргә, эшләр, хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 24 октябрендәге 327 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсендәге муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салынган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. II бүлекне түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

«2.2. Субсидия алу хокукына ия юридик зат түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

1) субсидия алу өчен гариза биргәнчегә кадәр 3 ел эчендә даими маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда лицензия таләпләрен бозмау;

2) милек хокукларында яисә башка законлы хокукларда пассажирлар йөртүне даими гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән сыйдырышлы һәм кирәкле күләмдә автомобиль транспортына хуҗа булу;

3) «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Балтач муниципаль районы территориясендә җайга салынган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга муниципаль контракт төзү;

4) социаль юл билетлары буенча гамәлдәге законнар нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә транспортта йөрү өчен ташламалар бирү белән билгеләнгән тәртиптә расланган пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга тарифлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда бастырырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов